ТАТАР ӘКИЯТЛӘРЕ

ТАТАРСКИЕ СКАЗКИ

Халык әкиятләре безне балачактан ук дулкынландыра һәм сокландыра килеп, зур булгач та эстетик ләззәт бирәләр. Чыннан да, кинәт кенә Каф тау артына, зәңгәр диңгезләр аръягына янсә кеше аягы басмаган карурманнар эченә барып төшү һәм тылсымчы картлар белән әкият баһадирлары арасына килеп керү кызык та, мавыктыргыч та түгелмени? Әйләнәтирәндә искиткеч вакыйгалар, баш әйләндергеч маҗаралар тулып ята, син бер шатланасың, бер борчуга төшәсең. Кайвакыт әкият кенә тыңламыйсың, бәлки бик талантлы һәм шаян күңелле рәссамның халык тормышыннан алып язган поэтик картинасын карыйсың шикелле.

Әкиятләр безне мавыктыргыч кызык булулары белән генә үзләренә тартмыйлар, аларга тирән мәгънә дә салынган. Халык үзенең гасырлар буенча тупланып килгән бай һәм катлаулы тормыш тәҗрибәсенең иң мөкатдәс, иң кадерле сөземтәсен әкиятләр аша буыннан-буынга тапшыра килгән. Аларда ватаныңа, туган ягыңа, хезмәткә мәхәббәт тә, эш сөючәнлек тә, өлкәннәргә, туганнарга, гомумән, кешегә тирән ихтирам да, гаделлек, хакыйкать өчен көрәш тә һәм ялганга, әшәкелеккә, изүчеләргә һәм дошманнарга нәфрәт тә бар.

Халык иҗаты элек-электән әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләрен яңа әсәрләр иҗат итәргә рухландырып килә. Н. Җиһановның «Алтын чәч» операсы, Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты, Н. Исәнбәтнең «Түләк» пьесасы әнә шундыйлардан. РСФСРның халык рәссамы Харис Якупов һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Лотфулла Фаттахов та халык әкиятләре темасына күп кенә рәсемнәр ясаганнар. Мондый әсәрләр әкияттәге вакыйгаларны, әкият геройларын һәм аларның батырлыкларын күз алдына китереп бастыралар, әкият эчтәлеген тагын да тирәнрәк ачып бирәләр.

Кыскасы, танылган рәссамнарның бу рәсемнәре халык иҗаты әсәрләрен тагын да тирәнрәк, киңрәк аңларга мөмкинлек тудыра һәм чын мәгънәсендә эстетик ләззәт бирә.

Гомәр Бәширов

Народные сказки начинают волновать и восхищать нас еще с детства, доставляют огромное эстетическое наслаждение и в зрелом возрасте. Разве не заманчиво вдруг очутиться где-то за синими морями-океанами, за горами и долами, в каком-то тридевятом государстве, в страшноватом диком краю, среди всемогущих волшебников и сказочных богатырей? А вокруг тебя происходят удивительные приключения, ожесточенные схватки, и ты переживаешь то бурную радость, то печалишься. Порою кажется, что не сказку слушаешь, а видишь очаровательную поэтическую картину жизни, созданную очень мудрым, очень одаренным и не унывающе веселым художником.

Эти чудесные творения народа покоряют нас не только тем, что они очень забавны и интересны. Они, как пчелиные соты медом, наполнены мудрым и глубоким смыслом. В своих сказках и легендах, пословицах и песнях народ из поколения в поколение передавал все самое дорогое и доброе, самое заветное и умное, что накопил за свою большую, многовековую историю: любовь к Родине и родной природе, стремление к свободе, уважение к людям, труду, доброте, справедливости и нетерпимость к обману, лжи, ненависть к поработителям, к врагам.

Устное творчество народов издавна вдохновляет деятелей искусства и литературы на создание новых художественных произведений. Таковы у нас опера Н. Жиганова «Алтынчеч», балет Ф. Яруллина «Шурале», пьеса Н. Исанбета «Туляк» и другие. Народный художник РСФСР Харис Якупов и заслуженный деятель искусств РСФСР Лутфулла Фаттахов создали интересные иллюстрации к сказкам. Похождения героев, обстоятельства их подвига и борьбы стали зримыми, иллюстрации еще глубже раскрывают содержание сказок.

Признанные наши художники, помогая еще полнее понять народные сказки, доставляют нам истинное удовольствие.

Гумер Баширов

... Ала айгыр шул сәгать егетне өстерәп утка алып кереп китте...

«Ак бүре» әкияте.
Л. А. Фаттахов рәсеме.

... И влетел в огонь пегий конь с джигитом...

Сказка «Белый волк».
Иллюстрация Л. А. Фаттахова.

Түгәрәк алан, көмеш күл!
Көмеш күлнең суы мул.
Соры бүре куып җитте,
Яшерсәнә, көмеш күл!
Яшерсәнә, көмеш күл!

«Гөлчәчәк» әкияте.
Л. А. Фаттахов рәсеме.

Озеро серебряное, полноводное!
Догоняет меня старуха-убыр.
Спрячь поскорей меня, озеро!
Укрой поскорей меня, озеро!

Сказка «Гульчечек».
Иллюстрация Л. А. Фаттахова.

... Хатын куыш карама янына килә:
— Мин карт кешегә кияүгә барган идем, бер дә яратмыйм, үземнең китәсем дә килми, байлыгы зур...
Ә карама эченнән аның ире киңәш бирә:
Картыңның колагын саңгырау, күзен сукырайтасың килсә, көн дә майлы ризык белән сыйла!

«Хәйләкәр мылтыкчы» әкияте.
Х. А. Якупов рәсеме.

... Приблизилась она к дуплу:
— Я вышла замуж за старика. Я его не люблю. Но он богат! Скажи, как мне быть?
А в дупле сидит ее муж, советует:
— Накорми его маслом, и он станет слепым и глухим...

Сказка «Хитрый стрелок».
Иллюстрация Х. А. Якупова.

Садыков А.Т.

— ... Тавык урынына миңа каз бирсәң дә ярар, — дигән төлке.

Хуҗа тавык урынына каз биреп җибәргән. Ә төлке өченче авылга барып, анда казны үгезгә алмаштырып алган...

«Хәйләкәр төлке» әкияте.
Х. А. Якупов рәсеме.

... — Раз так, то отдай мне гуся вместо курицы, — сказала лиса.

Хозяин отдал. А хитрая лиса пошла в третью деревню, чтобы обменять гуся на быка...

Сказка «Хитрая лиса».
Иллюстрация Х. А. Якупова.

Садыков А.Т.

... Солдат янә суккан чакма ташын, өченче эт килеп җиткән..

— Ни боерасыз?

— Акча кирәк!..

«Чакма ташы» әкияте.
Л. А. Фаттахов рәсеме.

... Солдат еще раз ударил кремнем о кремень, прибежала третья собака:

— Что прикажете?

— Давай деньги!

Сказка «Кремень».
Иллюстрация Л. А. Фаттахова.

... Дию пәрие ялына икән:

— Җибәрсәнә! Йортыгызга бүтән кермәс идем, бер нәрсәгезгә тимәс идем!..

«Тегүче, аю һәм шайтан» әкияте.
Х. А. Якупов рәсеме.

... А див скачет вокруг дерева и кричит:

— Отпустите меня, никогда в жизни не подойду к вашей избе!..

Сказка «Портной, медведь и бесенок».
Иллюстрация Х. А. Якупова.



... Алтын канатлы кошны кулына төшергәч, егет өенә кайтмак булды. Чулак вәзир, үзенең җилкәсенә атландырып, егетне очырып алып китте...

«Алтын балык» әкияте.
Х. А. Якупов рәсеме.

... Когда джигит достал золотокрылую птицу, захотелось ему вернуться домой. Везирь взяла его на спину, и они полетели.

Сказка «Золотая рыбка».
Иллюстрация Х. А. Якупова.

... Тузаннар туздырып, арттан дию пәрие килә. Әхмәт көзгене ала да юлга ташлый...

«Унберенче Әхмәт» әкияте.
Л. А. Фаттахов рәсеме.

... Разъярился див, еще быстрее бросился в погоню. Вынул Ахмет зеркало, размахнулся и бросил между собой и дивом...

Сказка «Одиннадцатый сын Ахмет».
Иллюстрация Л. А. Фаттахова.

... Усал җиңгәләре капны ачып караганнар икән, тугыз тукмак, сикереп чыгып, җиңгәләрен тукмакларга ябышты, ди...

«Таз» әкияте.
Л. А. Фаттахов рәсеме.

... Злые снохи развязали куль, а оттуда выскочили девять колотушек и давай их дубасить...

Сказка «Хитроумный Таз».
Иллюстрация Л. А. Фаттахова.

... Кәҗә эшнең кай тирәдә йөргәнен шундук аңлап ала да әче тавыш белән кычкырып та җибәрә.

— Ики-ки, мики-ки, капчыктагы бүре башы бит уники!..

«Кәҗә белән сарык» әкияте.
Х. А. Якупов рәсеме.

... Когда коза поняла, в чем дело, она закричала истошно:

«Ики-ки, мики-ки, в мешке двенадцать волчьих голов».

Сказка «Коза и овца».
Иллюстрация Х. А. Якупова.

... Егет бик тирән баз казыды, ди, баз авызына эшләпәсенең төбен тишеп куйды, ди. Пәри алтын акча ташый-ташый аптырап бетте, ди...

«Һөнәрле үлмәс» әкияте.
Х. А. Якупов рәсеме.

... Он выкопал глубокую яму, подставил дырявую шляпу, а пери выбивался из сил, все таская и таская золотые деньги...

Сказка «Умный джигит».
Иллюстрация Х. А. Якупова.

... Егет шүрәлегә әйткән:

— Мин өченче тапкыр чапканчы, син шунда бармагыңны кыстырып торсана, — дигән.

Шүрәле бармагын бүрәнә ярыгына куйган икән...

«Шүрәле» әкияте.
Х. А. Якупов рәсеме.

... Дровосек говорит:

— Засунь пальцы в щель, чтобы она не закрылась, а я ударю третий раз.

Сунул шурале пальцы в щель...

Сказка «Шурале».
Иллюстрация Х. А. Якупова.

Бәясе 60 тиен.

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1967

ТАТАРСКИЕ СКАЗКИ

Иллюстрации Х. А. Якупова и Л. А. Фаттахова

ТАТАР ӘКИЯТЛӘРЕ

Х. А. Якупов һәм Л. А. Фаттахов рәсемнәре

Редакторлары: Ф. Г. Гайнанова, М. Д. Зарецкий. Художество редакторы Б. М. Альменов. Техник редакторы Э. Я. Зарипов. Корректорлары: А. Ш. Зарипова, Р. М. Коротынская

Наборга бирелде 13/IV-1966 ел. Басарга кул куелды 14/VII-1967 ел. Офсет кәгазе 120 гр., 60×90¹/₈. Якынча басма табак 3. Учетн.-изд. табак 1,59. Заказ Н-573. ПФ 03187. Тираж 20000. Бәясе 60 тиен.

Татарстан китап нәшрияты, Бауман урамы, 19.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан. Бауман ур., 19. 1967 ел.